**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет «Балтачевского сельского поселения» Азнакаевского муниципального района**

ул. Молодежная, д 1а , с. Балтачево
Азнакаевского муниципального района
423302, Тел. (8-292) 4-47-23

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы «Балтач авыл жирлеге» башкарма комитеты**

Азнакай муниципаль районы, Балтач авылы,
Молодежный урамы, 1а
423302, Тел. (8-292) 4-47-23

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Башкарма комитеты Карары**

Балтач авылы № 10 01 август 2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү Тәртибе турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль закон, «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 02.05.2006 ел 59-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 12.05.2003 ел №16-ТРЗ Татарстан Республикасы законы» нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Башкарма комитеты карар чыгара:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирелеге Башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү Тәртибен расларга (№ 1 кушымта).
2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http//aznakayevo.tatar.ru. веб-адрес буенча урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Башлык Л.Л.Хэбипов

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Балтач авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына
кушымта №1
01.08.2019 ел №10

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү Тәртибе

1. Әлеге Тәртип 12.05.2003 ел № 16-ТРЗ «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законының 23 маддәсен үтәү йөзеннән эшләнгән һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау, гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау, җәмәгатьчелек фикерен һәм актуаль проблемаларны өйрәнү, гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү формаларын һәм методларын камилләштерү, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау сыйфатын күтәрү максатыннан үткәрелә.

3. Тиешле чорда гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау барлык мөрәҗәгатьләр, шул исәптән язма рәвештә, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган Интернет-кабул итү аша җибәрелгән электрон документ формасында, шулай ук вәкаләтле затларның гражданнарны кабул итү барышында кабул ителгән мөрәҗәгатьләр буенча гамәлгә ашырыла.

4. Кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау ел саен башкарыла.

5. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Башкарма комитеты сәркатибе хисап чорыннан соң килүче айның 10 числосына кадәр аналитик белешмә төзи.

6. Аналитик белешмәдә шәхси кабул итүдә кабул ителгән гражданнар саны, гражданнарны шәхси кабул итү буенча вәкаләтле затлар һәм күчмә кабул итү, мөрәҗәгатьләрнең тематикасы, мөрәҗәгатьләр нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар турында, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый һәм башка актлар турында (булган очракта) мәгълүмат булырга тиеш.

7. Җирле үзидарә органнарына кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләренә Анализ тиешле чорда узган елның шул ук чорында кергән гражданнар мөрәҗәгатьләре белән чагыштыру юлы белән үткәрелә.

8. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Башкарма комитет сәркатибе еллык аналитик белешмәне Азнакай муниципаль районының Интернет-мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында ел саен түбәндәге веб-адрес буенча : http://aznakayevo.tatarstan.ru “Гражданнар мөрәҗәгете” бүлегендә бүлегендә хисап чорыннан соң килүче айның 15 числосына кадәр урнаштыруны тәэмин итә.